**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы №13 «21» июль 2025 ел

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге Советының
2022 елның 15 декабрендәге 28 номерлы
«Җирле салымнар суммалары өлешендә
бурычны түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләре турында" карарына
үзгәрешләрне кертү хакында
( 07.06.2024 №16 карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 декабрендәге 28 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында" карарына (07.06.2024 №16 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.2. 2,3 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Җ.Закирова